КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 10 июль г.Казань № 562

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2019 ел, 10 июль, 562 нче карары белән расланган социаль-көнкүреш хезмәтләре, социаль-медицина хезмәтләре, социаль-психологик хезмәтләр, социаль-педагогик хезмәтләр, социаль-хезмәт хезмәтләре, социаль-хокукый хезмәтләр, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларындагы хезмәтләр, ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтүне кертеп, стационар һәм ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарга үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2019 ел, 10 июль, 562 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 19 апрель, 314 нче; 2019 ел, 28 июнь, 521 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган социаль-көнкүреш хезмәтләре, социаль-медицина хезмәтләре, социаль-психологик хезмәтләр, социаль-педагогик хезмәтләр, социаль-хезмәт хезмәтләре, социаль-

хокукый хезмәтләр, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларындагы хезмәтләр, ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтүне кертеп, стационар һәм ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1 нче пунктындагы 1.1 – 1.2.3 нче пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «1.1. | мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен | 1887,68 | 1950,49 | 1306,36 | 1344,43 |
| 1.1.1. | социаль-көнкүреш хезмәтләре | 427,19 | 427,19 | 282,01 | 282,01 |
| 1.1.2. | социаль-медицина хезмәтләре | 606,97 | 632,83 | 537,76 | 554,61 |
| 1.1.3. | социаль-психологик хезмәтләр | 22,95 | 22,95 | 24,12 | 24,12 |
| 1.1.4. | социаль-педагогик хезмәтләр | 676,73 | 706,19 | 327,75 | 342,73 |
| 1.1.5. | социаль-хезмәт хезмәтләре | 49,14 | 51,63 | 51,14 | 53,63 |
| 1.1.6. | социаль-хокукый хезмәтләр | 30,28 | 31,53 | 31,83 | 33,08 |
| 1.1.7. | социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның коммуникатив потен-циалын арттыру максатларында күрсәтелә торган хезмәтләр | 74,42 | 78,17 | 51,75 | 54,25 |
| 1.2. | озатып йөрүче затлар өчен | 470,30 | 482,78 | - | - |
| 1.2.1. | социаль-көнкүреш хезмәтләре | 165,59 | 165,59 | - | - |
| 1.2.2. | социаль-психологик хезмәтләр | 65,97 | 65,97 | - | - |
| 1.2.3. | социаль-педагогик хезмәтләр | 238,74 | 251,22 | - | -». |

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин